**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2023 елның «11» августыннан — № 177

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2022 елның 05 декабрендәге 359 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинның Татарстан Республикасында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча «юл картасын» гамәлгә ашыру мәсьәләсе һәм 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә конкуренцияне үстерүнең милли планын үтәү буенча бурычлар турында 2023 елның 15 маендагы АП-12-144 номерлы киңәшмәсе йомгаклары буенча йөкләмәләр исемлеген үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2022 елның 05 декабрендәге 359 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2022 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планы»ның кушымтасына «Ритуаль хезмәтләр базары» исемле 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 1.1. юлын өстәргә:

| № т/б | Чараның исеме | Максатчан индикатор | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор күрсәткече | | | | | Максатлы индикаторны исәпләү методикасы. | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | | |
| 1 | Зиратларда җирләү урыннары реестрын булдыру эшләре | Зиратлардагы җирләү урыннары реестрына кертелгән җирләү урыннары саны | % | 0 | 0 | 0 | 30 | 100 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ - зиратлардагы җирләү урыннары реестрына кертелгән җирләү урыннары саны $V_o$ - зиратлардагы җирләү урыннарының гомуми саны | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р. Р. Фасахов